**Балтач муниципаль районы**

**МБГБУ “Шубан ТГБМ”**

# “ ПЕСИ - ДӘВАЛАУЧЫ “

проект

3нче сыйныф

Җитәкчесе :Шарипова Л.У.

Башкаручы : Шарипова А.Р.

**2020 – 2021нче уку елы**

Эчтәлек

КЕРЕШ ________________________________________________ 3 бит

Төп өлеш _______________________________________________ 4-6 бит

1. Песиләр каян килеп чыккан ____________________________ 4бит

2. Песиләрнең үзенчәлекләре һәм аларның төрләре ( күрү,ис сизү ,тышкы кыяфәтләре, песиләрнең токымнары ) _________________________ 4 бит

3. Песиләрнең кешеләр янында яшәү үзенчәлеге _____________ 5 бит

4. Песи – дәвалаучы ______________________________________ 5 бит

5. Сынлы сәнгатьтә песи образы ___________________________ 5 бит

Практик өлеш ( эксперимент) _______________________________ 5бит

Йомгаклау ______________________________________________ 5-6 бит

Кулланылган әдәбият исемлеге ______________________________ 7 бит

Кереш

Без бу дөньяда хайваннардан башка яшәүне күз алдына китерә дә алмыйбыз.Һәрбер кешегә нинди дә булса җәнлек яки йорт хайваны ошый .Минем яраткан хайваным – ул песиләр.Алар төрле – төрле, ләкин һәрберсе бәйсез һәм горур . Аларны кем шундый иткән ?Бәлки табигать , бәлки кешеләр, бәлки алар үзләре һәрвакыт шундый булганнардыр? Үземнең танышларым арасында мин сорашу үткәрдем һәм шуны ачыкладым :күп кенә песи хуҗалары аларны ничек тәрбияләү , ашату, дәвалау турында мәгълүматлы түгел .Шуның өчен мин бу теманы якыннан өйрәнергә булдым .

**МАКСАТ :** кешеләр тормышында песиләрнең нинди әһәмияткә ия булуларын билгеләү

**БУРЫЧЛАР:**

1. Песиләр турында теоретик материал эзләү,уку.

2. Песиләрнең үзенчәлекләрен ачыклау.

3. Песиләрнең кешеләр янында яшәү үзенчәлекләрен билгеләү.

4. Халык телендә ни өчен песи – дәвалаучы дип йөртүләрен ачыклау.

5. Сәнгать өлкәсендә песи образының нинди роль уйнавын билгеләү.

6. Анкета үткәрү .

**Гипотеза :** әгәр песиләрне яратып ,алар турында кайгыртып, дөрес тәрбияләсәң ,алар дәвалаучы да , матурлыклыкларына сокландыручы да була алалар.

**Өйрәнү объекты** : өемдә яшәүче песи

**Өйрәнү предметы :** песиләрнең үз-үзләрен тотышы

**Өйрәнү предметы:** күзәтү,гомумиләштерү,эксперимент

## Төп өлеш

### 1. Песиләрнең килеп чыгышы

Песиләр безнең дүрт аяклы, сыйпап , яратып торганда канәгать булуын белдереп.,йомшак кына мырлап торучы дустыбыз.Һәрберебез дә песиләрнең тышкы кыяфәтен яхшы күз алдына китерә. Ләкин песиләрнең үзенчәлекләре һәм безнең тормышыбызга аларның каян килеп керүе турында барыбыз да белми.

Бүгенге көндә песи үзе кешеләрне эзләп килгәнме, яисә кеше беренче булып песине үз өенә алып кайтканмы, әйтүе кыен .Шунысы билгеле : песинең кешеләр янында яшәве зур файда китерә.

Тарихи чыганаклардан песиләрнең килеп чыгышы турында шунысы билгеле , аларның күпгасырлы тарихы бар.Моннан 30-35 миллион еллар элек борынгы кыргый песиләр булуы билгеле .

Хәзерге галимнәрнең күбесе йорт песиләре безнеэ эрага кадәр 4000еллар элек Борынгы Мисырның Нил елгасы үзәнлекләрендә килеп чыккан дип аңлата. Бу песиләрнең бабалары дип Ливия,Нубия песиләре санала.

Күпгасырлы тарихы булуга карамастан,башка хайваннар белән чагыштырганда , бүгенге көндә песиләрнең кешеләр белән мөнәсәбәтендә үзгәрешләр аз.Тышкы кыяфәте белән дә ул борынгы бабаларыннан әллә ни аерылып тормый. Бары тик колаклары төзелешендә,йөзенең йомрылануында һәм төсе үзгәрүдә генә аерма бераз сизелә.

2. Песиләрнең үзенчәлекләре һәм төрләре ( күрү,ис сизү,тышкы кыяфәте,песиләрнең токымнары )

Песиләрнең йөрәкләре кешенекеннән ике тапкырга күбрәк, минутына 140 тапкыр тибә.Сөякләр саны да безнекеннән 40 ка күбрәк.Песинең колагы 180 градуска әйләнә ала.Һәр колагында 32 мускул.Аларның ис сизү сәләте кешеләрнеке белән чагыштырганда 14 тапкырга көчлерәк. Песиләр гадәттә 15 елга кадәр яшиләр.Тәүлегенә 16 сәгать йоклыйлар.Калган вакытларын үзләрен тәрбияләүгә багышлыйлар . Алар яхшы ишетәләр, күзләре яхшы күрә, озын мыеклары бар ,йөгергән вакытта бармак араларыннан озын тырнаклары калкып чыга.

Песиләр оста акробатлар.Аның алгы аяклары төрле якка борыла , гәүдәсенең һәр ике өлеше капма-каршы якка хәрәкәтләнә ала .

Алгы аякларында биш бармак , ә арткы аякларында бармаклары дүртәү генә . Ишетүе кешеләрнекеннән һәм этләрдән яхшырак.

Күзләре ,нәкъ кешеләрнеке кебек, икесе дә бер тарафка карап тора. Бу күзләр яктыда да караңгы төшә башлаган вакытта да яхшы күрәләр. Песиләрнең күз каралары яктылыкка карап формаларын үзгәртү сәләтенә ия. Дөм караңгы булганда песиләр күрмиләр.

**Токымнары :**песиләрнең 30 лап токымы булуы билгеле. Бик озын йонлы- йонлач , уртача һәм кыска йонлы песиләр була. Мәсәлән , сиам токымлы песи, рус токымлы песи ,ангора песие,фарсы песие,сфинкс һ.б.

**3. Йорт шартларында яшәүче песиләрнең үзенчәлекләре**

Песи бәйсез җан иясе булса да , ул хуҗасының игътибарына бик мохтаҗ.

Аның белән аралашырга, сөйләшергә ,уйнарга кирәк.Әгәр песигә игътибарлы булмасаң, аның кәефе төшә , күңелсез була башлый. Шулай ук песине һәркөнне тәрбияләп тору да мөһим. Вакытында тырнакларын кисеп торырга, көн саен йонын тарарга,колакларын чистартырга , прививкалар ясатырга кирәк.

Песиләр сөйләшә белми ,чөнки сөйләшү аларга кирәк тә түгел.Ләкин алар үзләренең хисләрен,эмоцияләрен гәүдә тотышлары һәм мимикалары белән белдерә алалар. Песинең мырлавы аның тавыш яралгыларыннан чыкмый.Бу мырлау песинең гәүдәсенең өске өлеше вибрациясе нәтиҗәсендә барлыкка килә . Песигә хөрмәт вакытында күрсәтелергә тиешлеген истә тотарга кирәк.Әгәп песи хуҗасының сыйпавын теләсә, сыйпарга, тынычлыкта калырга теләсә, үзен генә калдыру мөһим.

**4. Песи – дәвалаучы**

Песиләр белән бергә яшәгән һәрбер кеше белүенчә **,** бу затлар күп нәрсәләргә сәләтле.Хәтта тылсымга да.Песиләр авыруларны да дәвалыйлар,балаларны да йоклаталар,җырлыйлар да, хәтта каракларны да тоталар.

Тикшерүләр күрсәткәнчә , песиләр белән яшәүче кешеләр үз яшьтәшләренә караганда 4-5 елга күбрәк яшиләр. Алар ялгызлыкта иптәш ,тынычландыручы,югары кан басымын төшерәләр ,йөрәк эшчәнлеген көйлиләр, кан тамырлары һәм баш авыртуын алалар, травмаларның тазаруын тизләтәләр,эчке ялкынсыну авыруларын дәвалыйлар.Песинең дәвалау йогынтысы кешегә песине сыйпаганда уч төбе һәм бармаклары аша тәэсир итә.

Башка йорт хайваннарыннан аермалы буларак ,песиләр үз хуҗасының сәламәтлегенә уңай тәэсир итәләр.

**5. Сәнгать өлкәсендә песи образы.**

Песиләр европалылар һәм рус фольклорында киң яктыртыла. Песиләр катнашында балалар өчен күптөрле мультфильмнар , зурлар өчен кинофильмнар, песиләр игътибарга лаек урынны алып торган әсәрләр иҗат ителгән. Никадәр атаклы рәссамнар үз картиналарында песиләрне сурәтләгән !

**Песиләр әдәбиятта**

Әдәбиятта песиләр башка хайваннарга караганда ныграк нигезләнгәннәр.

Россиядән алып Кытайга кадәрге барлык халыклар мәдәниятында песиләр турындагы мәсәл һәм экиятләр бар.

**Сынлы сәнгать һәм песиләр.**

Песиләрне беренчеләрдән булып Борынгы Мисырда ясый башлаганнардыр , мөгаен.Чөнки Мисырдагы байларның каберлек стеналарында песиләрне Баст алиһәгә тиңләп, аларның рәсемнәрен ясаганнар. Ерак Көнчыгышта Кытайлар үзләренең нәсел символлары буларак песи сурәтләрен ефәк тукымага төшергәннәр.

**Мультфильмнарда песиләр**

Песиләр- мәңгелек мультфильм йолдызлары һәм комиклар .Тома һәм Джери дебюты 1940нчы елда була .

**Практик өлеш**

Тәжрибә

Тәжрибәнең максаты : практик ысул белән песинең гаилә әгъзаларының кайсысын үз хуҗасы итеп санавын билгеләү

Тәжрибә үткәрү :мин һәм әнием песине чакырдык.Песи шунда ук минем яныма килде.

Нәтиҗә : безнең песи мине үз хуҗасы итеп саный .

**Йомгаклау**

Көндәлек күзәтүләрдән чыгып шуны әйтергә була : песиләр кешеләр тормышында зур әһәмияткә ия. Ул кешеләрдәге тискәре импкльсларны үзенә ала һәм энергетиканы чистарта . Минем әгәр песиләрне яратсаң, вакытында тиешле игътибарны күрсәтсәң, тәрбия кылсаң ,яратсаң, ул сиңа тугры дус та , дәвалаучы да , соклану объекты да була ала дигән гипотезам исбатланды.Минем шундый яхшы дустым булуга мин бик шатланам .Кемнәр өчендер песиләр ярдәмче, икенчеләр өчен тугры дус, ә кемнәр өчендер матурлык бирүче булып санала. Минем өчен исә песием тугры дус ,ул мине дәшми генә тыңлый һәм һәрвакыт ярдәм итәргә әзер тора.

Кулланылган әдәбият

1.